**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№71**
**14.01.2019**

Башкарма комитетның 2017 елның 1 ноябрендәге 6671 нче карары белән расланган сатулар үткәрмичә җир кишәрлеген сату-алу килешүе төзегәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан җир кишәрлекләрен сату бәясен билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.4 маддәсендәге 2 пунктның 3 пунктчасы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен биләү, файдалану, аның белән идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында нигезнамәнең 12 пунктының 9 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2017 елның 1 ноябрендәге 6671 нче карары белән расланган сатулар үткәрмичә җир кишәрлеген сату-алу килешүе төзегәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан җир кишәрлекләрен сату бәясен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктта:

- 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) коммерцияле булмаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләренә бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән җир кишәрлекләрен, гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләреннән тыш, шундый ширкәт әгъзаларына;»;

- 6 пунктчадагы «, дача хуҗалыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җир кишәрлегенең кадастр бәясенең унбиш процентына тигез бәя белән индивидуаль торак төзелеше максатларында, территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлекләрен әлеге коммерцияле булмаган оешмага сату гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин